**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Экологический кодекс Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 декабря 2018 года

## Статья 1

Внести в Экологический кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 40 (часть I), № 44 (часть I); 2017, № 27 (часть I); 2018, № 54 (часть I) следующие изменения:

1) статью 15 изложить в следующей редакции:
«Статья 15. **Основы экологического нормирования**

1. Экологическое нормирование осуществляется в целях гарантирующего сохранение благоприятной окружающей среды и обеспечение экологической безопасности государственного регулирования хозяйственной и (или) иной деятельности для предотвращения и (или) снижения ее негативного воздействия на окружающую среду.
2. Экологическое нормирование заключается в установлении нормативов качества окружающей среды, нормативов допустимого воздействия на окружающую среду при осуществлении хозяйственной и (или) иной деятельности.»;

2) статью 16 изложить в следующей редакции:
«Статья 16. **Требования к разработке экологических нормативов**

Разработка экологических нормативов включает в себя:
1) проведение научно-исследовательских работ для обоснования экологических нормативов;

2) установление оснований для разработки или пересмотра экологических нормативов;

3) утверждение и опубликование экологических нормативов в установленном порядке;

4) оценку и прогнозирование экологических, социальных, экономических последствий применения экологических нормативов.»;

3) статью 17 изложить в следующей редакции:

«Статья 17. **Нормативы качества окружающей среды**

1. Нормативы качества окружающей среды устанавливаются для оценки состояния окружающей среды в целях обеспечения благоприятных условий жизнедеятельности человека, рационального использования природных ресурсов, сохранения естественных экологических систем, генетического фонда растений, животных и других организмов.

2. К нормативам качества окружающей среды относятся:

1) нормативы, установленные для химических показателей состояния окружающей среды, в том числе нормативы предельно допустимых концентраций;

2) нормативы, установленные для физических показателей состояния окружающей среды, в том числе показателей уровней радиоактивности;

3) нормативы для биологических показателей состояния окружающей среды, в том числе видов и групп растений, животных и других используемых как индикаторы качества окружающей среды организмов;

4) иные нормативы качества окружающей среды.

3. Нормативы качества окружающей среды устанавливаются на основании результатов лабораторных испытаний, а также для территорий и акваторий на основании данных наблюдений за состоянием окружающей среды.

4. При установлении нормативов качества окружающей среды используются показатели, контроль за которыми обеспечивается посредством применения соответствующих методик (методов) измерений, способов индикации и тестирования.

5. Порядок разработки, установления и пересмотра нормативов качества окружающей среды устанавливается в соответствии с федеральным законодательством.

6. В целях сохранения окружающей среды и обеспечения экологической безопасности в Республике Татарстан утверждаются республиканские нормативы качества окружающей среды, содержащие соответствующие требования и нормы не ниже требований и норм, установленных на федеральном уровне.»;

4) статью 18 изложить в следующей редакции:

«Статья 18. **Нормативы допустимого воздействия на окружающую среду**

1. В целях предотвращения негативного воздействия на окружающую среду хозяйственной и (или) иной деятельности устанавливаются следующие нормативы допустимого воздействия на окружающую среду:

1) нормативы допустимых выбросов, нормативы допустимых сбросов;
2) технологические нормативы;
3) технические нормативы;
4) нормативы образования отходов и лимиты на их размещение;
5) нормативы допустимых физических воздействий (уровни воздействия тепла, шума, вибрации и ионизирующего излучения, напряженности электромагнитных полей и иных физических воздействий);
6) нормативы допустимого изъятия компонентов природной среды;
7) нормативы допустимой антропогенной нагрузки на окружающую среду.

2. Соблюдение нормативов допустимого воздействия на окружающую среду, за исключением технологических нормативов и технических нормативов, должно обеспечивать соблюдение нормативов качества окружающей среды.

3. Юридические лица и индивидуальные предприниматели за превышение нормативов допустимого воздействия на окружающую среду в зависимости от причиненного окружающей среде вреда несут ответственность в соответствии с законодательством.»;

5) статью 19 изложить в следующей редакции:

«Статья 19. **Нормативы допустимых выбросов, нормативы допустимых сбросов**

1. Нормативы допустимых выбросов, нормативы допустимых сбросов определяются для стационарного источника и (или) совокупности стационарных источников загрязнения окружающей среды в отношении загрязняющих веществ, включенных в перечень загрязняющих веществ, установленный Правительством Российской Федерации, расчетным путем на основе нормативов качества окружающей среды, в том числе нормативов предельно допустимых концентраций, с учетом фонового состояния компонентов природной среды.

2. Расчет или установление нормативов допустимых выбросов, нормативов допустимых сбросов осуществляется в соответствии с федеральным законодательством.»;

6) в статье 34:

а) пункт 4 признать утратившим силу;

б) в пункте $4^1$ слова «на землях» заменить словами «в границах»;

7) в статье 95:

а) часть 1 после слов «допустимого воздействия на водные объекты,» дополнить словами «технологические нормативы, установленные в соответствии с Федеральным законом от 10 января 2002 года № 7-ФЗ «Об охране окружающей среды»,»;

б) часть 2 признать утратившей силу;

в) пункт 1 части 6 после слов «в водных объектах» дополнить словами «или технологических нормативов, установленных в соответствии с Федеральным законом от 10 января 2002 года № 7-ФЗ «Об охране окружающей среды»;

8) в части 3 статьи 97 второе предложение изложить в следующей редакции: «Положение об охранных зонах гидроэнергетических объектов, включающее в себя порядок установления охранных зон для указанных объектов, особые условия водопользования и использования участков береговой полосы (в том числе участков примыкания к гидроэнергетическим объектам) в их границах, утверждается в соответствии с федеральным законодательством.»;

9) в статье 98:

а) часть 1 после слов «береговой линии» дополнить словами «(границам водного объекта)»;

б) в части 3 слова «соответствующей береговой линии» заменить словами «местоположения соответствующей береговой линии (границы водного объекта)»;

в) в части 12 слова «береговой линии» заменить словами «местоположения береговой линии (границы водного объекта)»;

г) в части 16 слова «на местности» исключить, после слов «в том числе» дополнить словами «обозначение на местности»;

10) статью 120 изложить в следующей редакции:

«Статья 120. **Федеральный государственный лесной надзор (лесная охрана)**

Федеральный государственный лесной надзор (лесная охрана) осуществляется органами исполнительной власти Республики Татарстан в случае передачи им полномочий Российской Федерации по осуществлению федерального государственного лесного надзора.»;

11) статью $135^6$ изложить в следующей редакции:

«Статья $135^6$. **Федеральный государственный охотничий надзор**

Федеральный государственный охотничий надзор осуществляется органами исполнительной власти Республики Татарстан в случае передачи им полномочий Российской Федерации по осуществлению федерального государственного охотничьего надзора.».

**Статья 2**

Пункт 19 статьи 1 Закона Республики Татарстан от 11 апреля 2015 года № 23-ЗРТ «О внесении изменений в Экологический кодекс Республики Татарстан и признании утратившими силу отдельных положений законодательных актов Республики Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2015, № 4) признать утратившим силу.

**Статья 3**

Настоящий Закон вступает в силу через 10 дней после дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
22 декабря 2018 года
№ 108-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“15 статья. **Экологик нормалаштыру нигезләре**

1. Экологик нормалаштыру уңайлы әйләнә-тирә мохитне саклауны һәм экологик иминлекне тәэмин итүне гарантияли торган, хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яисә) киметү өчен шушы эшчәнлекне дәүләт җайга салуы максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Экологик нормалаштыру әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларын, хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекне гамәлгә ашырганда әйләнә-тирә мохиткә йогынтының мөмкин нормативларын билгеләүдән гыйбарәт.”;

2) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“16 статья. **Экологик нормативларны эшләүгә таләпләр**

Экологик нормативларны эшләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

1) экологик нормативларны нигезләү өчен фәнни-тикшеренү эшләрен башкару;

2) экологик нормативларны эшләү яисә яңадан карау нигезләрен билгеләү;

3) экологик нормативларны билгеләнгән тәртиптә раслау һәм бастырып

чыгару;

4) экологик нормативларны куллануның экологик, социаль, икътисадый нәтиҗәләрен бәяләү һәм фаразлау.”;

3) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“17 статья. **Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары**

1. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары кеше яшәешенең уңайлы шартларын тәэмин итү, табигать ресурсларыннан рациональ файдалану, табигый экологик системаларны, үсемлекләрнең, хайваннарның һәм башка организмнарның генетик фондын саклап калу максатларында әйләнә-тирә мохитнең торышын бәяләү өчен билгеләнә.

2. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларына түбәндәгеләр керә:

1) әйләнә-тирә мохит торышының химик күрсәткечләре өчен билгеләнгән нормативлар, шул исәптән иң чик мөмкин булган концентрацияләр нормативлары;

2) әйләнә-тирә мохит торышының физик күрсәткечләре, шул исәптән радиоактивлык дәрәҗәләре күрсәткечләре өчен билгеләнгән нормативлар;

3) әйләнә-тирә мохит торышының биологик күрсәткечләре, шул исәптән әйләнә-тирә мохитнең сыйфат индикаторлары буларак кулланыла торган үсемлекләр, хайваннар һәм башка организмнар төрләре һәм төркемнәре өчен билгеләнгән нормативлар;

4) әйләнә-тирә мохитнең башка сыйфат нормативлары.

3. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары лаборатор сынаулар нәтиҗәләре, шулай ук территорияләр һәм акваторияләр өчен әйләнә-тирә мохит торышын күзәтүдән алынган белешмәләр нигезендә билгеләнә.

4. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларын билгеләгәндә, аларны тикшереп тору тиешле үлчәү методикаларын (ысулларын), индикация һәм тестлар үткәрү алымнарын куллану ярдәмендә тәэмин ителә торган күрсәткечләр кулланыла.

5. Әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативларын эшләү, билгеләү һәм яңадан карау федераль законнар нигезендә билгеләнә.

6. Татарстан Республикасында әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик иминлекне тәэмин итү максатларында әйләнә-тирә мохитнең федераль дәрәҗәдә билгеләнгән таләпләрдән һәм нормалардан түбән булмаган тиешле таләпләре һәм нормалары булган республика сыйфат нормативлары раслана.”;

4) 18 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“18 статья. **Әйләнә-тирә мохиткә йогынтының мөмкин нормативлары**

1. Хуҗалык һәм (яисә) башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмый калу максатларында әйләнә-тирә мохиткә йогынтының түбәндәге мөмкин булган нормативлары билгеләнә:

1) һавага чыгаруның мөмкин нормативлары, чыгарып ташлауның мөмкин нормативлары;

2) технологик нормативлар;

3) техник нормативлар;

4) калдыкларны барлыкка китерү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары;

5) физик йогынтыларның мөмкин нормативлары (җылылык, тавыш, вибрация, һәм ионлы нурланыш, электр магниты кырлары киеренкелеге йогынтысының һәм башка физик йогынтыларның дәрәҗәләре);

6) табигать мохите компонентларын аерып алуның мөмкин нормативлары;

7) әйләнә-тирә мохиткә антропоген йөкләнешнең мөмкин нормативлары.

2. Әйләнә-тирә мохиткә йогынтының мөмкин нормативларын үтәү, технологик нормативлардан һәм техник нормативлардан тыш, әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары үтәлешен тәэмин итәргә тиеш.

3. Юридик затлар һәм индивидуаль эшкуарлар әйләнә-тирә мохиткә йогынтының мөмкин нормативларын арттырган өчен әйләнә-тирә мохиткә китерелгән зыянга бәйле рәвештә законнар нигезендә җаваплы булалар.";

5) 19 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"19 статья. **Һавага зарарлы матдәләр чыгаруның мөмкин нормативлары, зарарлы матдәләр чыгарып ташлауның мөмкин нормативлары**

1. Һавага зарарлы матдәләр чыгаруның мөмкин нормативлары, зарарлы матдәләр чыгарып ташлауның мөмкин нормативлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән пычраткыч матдәләр исемлегенә кертелгән пычраткыч матдәләргә карата әйләнә-тирә мохитне пычратуның стационар чыганагы һәм (яисә) стационар чыганаклар җыелмасы өчен әйләнә-тирә мохитнең сыйфат нормативлары, шул исәптән иң чик мөмкин концентрацияләр нормативлары нигезендә, табигать мохите компонентлары фонының торышын исәпкә алып, исәпләү юлы белән билгеләнә.

2. Һавага зарарлы матдәләр чыгаруның мөмкин нормативларын, зарарлы матдәләр чыгарып ташлауның мөмкин нормативларын исәпләү яисә билгеләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.";

6) 34 статьяда:

а) 4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

б) $4^1$ пунктта "җирләрендә" сүзен "чикләрендә" сүзенә алмаштырырга;

7) 95 статьяда:

а) 1 өлештә "су объектларына йогынты ясауның мөмкин нормативлары" сүзләреннән соң ", "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән технологик нормативлар" сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) 6 өлешнең 1 пунктында "концентрацияләре нормативларыннан" сүзләреннән соң "яисә "Әйләнә-тирә мохитне саклау турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән технологик нормативлардан" сүзләрен өстәргә;

8) 97 статьяның 3 өлешендә икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Гидроэнергетик объектлар өчен саклау зоналары билгеләү тәртибе, сулардан файдалануның һәм яр буе полосасы кишәрлекләреннән (шул исәптән гидроэнергетик объектларга килеп кушылу кишәрлекләреннән) аларның чикләрендә файдалануның махсус шартлары кергән әлеге объектларның саклау зоналары турындагы нигезләмә федераль законнар нигезендә раслана.”;

9) 98 статьяда:

а) 1 өлештә “яр буе линиясенә” сүзләреннән соң “(су объекты чигендә)” сүзләрен өстәргә;

б) 3 өлештә “тиешле яр буе линиясеннән” сүзләрен “тиешле яр буе линиясе урнашкан урыннан (су объекты чигеннән)” сүзләренә алмаштырырга;

в) 12 өлештә “яр буе линиясеннән” сүзләрен “яр буе линиясе урнашкан урыннан (су объекты чигеннән)” сүзләренә алмаштырырга;

г) 16 өлештә “Урында” сүзен төшереп калдырырга, “шул исәптән” сүзләреннән соң “урында махсус мәгълүмат тамгалары билгеләп кую” сүзләрен өстәргә;

10) 120 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“120 статья. **Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманнарны саклау)**

Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урманнарны саклау) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан, аларга Россия Федерациясенең федераль дәүләт урман күзәтчелеген гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган очракта, башкарыла.”;

11) $135^6$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“$135^6$ статья. **Федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге**

Федераль дәүләт аучылык күзәтчелеге Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан, аларга Россия Федерациясенең федераль дәүләт аучылык күзәтчелеген гамәлгә ашыру вәкаләтләре тапшырылган очракта, башкарыла.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасы Экология кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында” 2015 елның 11 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 19 пунктын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 4) үз көчен югалткан дип танырга.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 22 декабрь
№ 108-ТРЗ